ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**24.03.2023ел**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 845**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 18 декабрендәге 2461 номерлы карары белән расланган, мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләре бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалы гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтү һәм мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга өстәмә компенсация бирү тәртибен унификацияләү максатларында, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2023 елның 11 февралендәге 20-09/2163 номерлы хаты нигезендә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 18 декабрендәге 2461 номерлы карары белән расланган (2019 елның 28 декабрендәге 2587 номерлы, 2021 елның 02 февралендәге 141 номерлы, 2021 елның 30 апрелендәге 1006 номерлы карарларына кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләре бирү тәртибенә 1.3 пунктындагы беренче, икенче абзацларына үзгәрешләр кертергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Компенсация алу хокукын билгеләгәндә гаиләнең җан башына уртача кереме Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өч яшькә кадәрге балалары булган гаиләләргә дарулар сатып алуга түләү турында» 2019 елның 03 декабрендәге 1095 номерлы карары белән билгеләнгән кагыйдәләр буенча исәпләнә

Компенсация билгеләгәндә гаиләнең җан башына уртача кереме компенсация билгеләү турында гариза бирү аена кадәрге соңгы 12 календарь айдагы (алга таба – исәп-хисап чоры) гаилә әгъзаларының керемнәре суммасыннан чыгып билгеләнә.

2. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлеге башлыгына әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында, Интернет челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы А.В. Старостин